**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 февраль № 84

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 7 февраль, 67 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 7 февраль, 67 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 4 октябрь, 716 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктның «ж» пунктчасында «Россия Федерациясенең бюджет законнарын һәм бюджетта хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган бүтән норматив хокукый актларны бозып» сүзләрен төшереп калдырырга;

11.1 пунктның «б» пунктчасында «язмача кире кагулар» сүзләрен «язма рәвештә кире кагулар» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта «яки» сүзен «һәм (яки)» сүзләренә алмаштырырга;

43 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«43. Тикшерү объекты камераль тикшерү актын алган көннән соң 10 эш көне эчендә актка карата язма рәвештә кире кагу бирергә хокуклы, алар тикшерү

материалларына теркәлә. Кире кагулар тапшыру турында хәбәрнамә белән кулга бирелә торган яки заказлы почта юлламасы белән җибәрелә.»;

51 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзләренә карата капма-каршы тикшерү үткәрелә торган затлар һәм оешмалар күчмә тикшерү (ревизия) тематикасына кагылышлы мәгълүмат, документлар һәм материалларны танышу өчен, ә тикшерү (ревизия) төркеме җитәкчесенең язмача соравы (таләбе) буенча күчмә тикшерү (ревизия) тематикасына кагылышлы документлар һәм материаллар күчермәләрен бирергә тиеш, алар капма-каршы тикшерү тәмамланганнан соң күчмә тикшерү (ревизия) материалларына теркәлә»;

61 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«61. Тикшерү объекты күчмә тикшерү актын алган көннән соң 10 эш көне эчендә актка карата язма рәвештә кире кагу бирергә хокуклы, алар тикшерү материалларына теркәлә. Кире кагулар тапшыру турында хәбәрнамә белән кулга бирелә торган яки заказлы почта юлламасы белән җибәрелә.»;

63 пунктның «в» пунктчасында «язмача кире кагулар» сүзләрен «язма рәвештә кире кагулар» сүзләренә алмаштырырга;

64 пунктның «а» пунктчасында «документта күрсәтелгән вакытларда» сүзләреннән соң «яки, әгәр вакыты күрсәтелмәсә, аны алган көннән соң 30 календарь көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

65 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«65. Әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы «б» пунктчасында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Министрлык сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын һәм бүтән норматив хокукый актларны бозуны бетерү хакында күрсәтмә җибәрә. Бу чакта әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы «б» пунктчасының икенче – дүртенче абзацларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында күрсәтелгән күрсәтмәләр сатып алулар башланганчы бирелә.»;

70 пунктта «Россия Федерациясенең бюджет законнарын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган бүтән норматив хокукый актларны бозып» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\84.docx